**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 21 июлендәге 2316 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабрендәге 4770 номерлы «Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе хакында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон, 2024 елның 22 июлендәге 187-ФЗ номерлы «“Эскроу счетларыннан файдаланып төзелеш подряды килешүләре буенча торак йортлар төзү турында”гы федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләп чыгару һәм раслау тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабрендәге 4770 номерлы «Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе хакында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карары кушымтасына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 7 ноябрендәге 3371 номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 4381 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 номерлы кушымтаны әлеге карар кушымтасы нигезендәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 21 июлендәге
2316 номерлы карарына кушымта
(Форма)

**Шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзүне яки реконструкцияләүне тәмамлау турында хәбәрнамә**

20______ елның «___»______________

_______________________________________________________________________________

(төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының, Россия Федерациясе субъектындагы башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының исеме)

## 1. Төзүче турында белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Физик зат төзүче булып торган очракта физик зат турында мәгълүматлар: | |
| 1.1.1 | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | |
| 1.1.2 | Яшәү урыны | |
| 1.1.3 | Шәхесне таныклый торган документның реквизитлары | |
| 1.2 | Юридик зат төзүче булып торган очракта, юридик зат турында мәгълүматлар: | |
| 1.2.1 | Атамасы | |
| 1.2.2 | Урнашкан урыны адресы | |
| 1.2.3 | Юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очрактан тыш) | |
| 1.2.4 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очрактан тыш) | |

## 2. Җир кишәрлеге турында белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 2.1 | Җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта) | |
| 2.2 | Җир кишәрлеге урнашкан урынның адресы яки тасвирламасы | |
| 2.3 | Төзүченең җир кишәрлегенә булган хокукы турында белешмәләр (хокук билгеләүче документлар) | |
| 2.4 | Башка затларның җир кишәрлегенә булган хокуклары турында белешмәләр (булган очракта) | |
| 2.5 | Җир кишәрлеген файдалануның рөхсәт ителгән төре турында белешмәләр | |

## 3. Капиталь төзелеш объекты турында белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 3.1 | Капиталь төзелеш объектыннан (шәхси торак төзелеше объектыннан яки бакча йортыннан) рөхсәт ителгән файдалану төре турында белешмәләр | |
| 3.2 | Хәбәрнамә бирүнең максаты (төзү яки реконструкцияләү) | |
| 3.3 | Параметрлар турында белешмәләр: | |
| 3.3.1 | Җир өстендәге катлар саны | |
| 3.3.2 | Биеклеге | |
| 3.3.3 | Җир кишәрлеге чикләреннән чыгу турында белешмәләр | |
| 3.3.4 | Төзелеш мәйданы | |

**4. Җир кишәрлегендә төзелгән яки реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының схема сурәте**

**5. Эскроу счеты файдаланылган төзелеш подряды килешүе турында белешмәләр (2024 елның 22 июлендәге 186-ФЗ номерлы «Эскроу счетларыннан файдаланып төзелеш подряды килешүләре буенча торак йортлар төзү турында»гы федераль закон нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзегән очракта)**

| | | |
|---|---|---|
| 5.1 | Номеры | |
| 5.2 | Төзелү көне | |
| 5.3 | Төзелү урыны | |
| 5.4 | Төзелеш подряды килешүе турында белешмәләрне торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына кертү көне | |

**6. Эскроу счетыннан файдаланып, төзелеш подряды килешүе нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзү эшләрен башкаручы подрядчы турында белешмәләр (2024 елның 22 июлендәге 186-ФЗ номерлы «Эскроу счетларыннан файдаланып төзелеш подряды килешүләре буенча торак йортлар төзү турында»гы федераль закон нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзегән очракта)**

| | | |
|---|---|---|
| 6.1 | Юридик зат подрядчы булып торган очракта, юридик зат турында мәгълүматлар | |
| 6.1.1. | Атамасы | |
| 6.1.2. | Урнашкан урыны адресы | |
| 6.1.3 | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәве номеры | |
| 6.1.4 | Салым түләүченең идентификация номеры | |
| 6.1.5 | Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында бирелгән уникаль идентификация коды (идентификатор) | |
| 6.2 | Подрядчы шәхси эшмәкәр булган очракта, шәхси эшмәкәр турында белешмәләр: | |
| 6.2.1 | Фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) | |
| 6.2.2 | Россия Федерациясендә яшәү урыны буенча теркәлүе турында белешмәләр | |
| 6.2.3 | Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында шәхси эшмәкәрне теркәү турында язманың дәүләт теркәү номеры | |
| 6.2.4 | Салым түләүченең идентификация номеры | |
| 6.2.5 | Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында бирелгән уникаль идентификация коды (идентификатор) | |

Элемтә өчен почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы:

__________________________________________________________________________

Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе хакында яки төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәве хакында хәбәрнамәне түбәндәге ысул белән җибәрүегезне сорыйм:

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

(почта адресына һәм (яки) электрон почта адресына җибәрү юлы белән яки төзелешкә рөхсәтләр бирү вәкаләте булган федераль башкарма хакимият органында, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органында яки җирле үзидарә органында, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша кулга биреп)

Әлеге хәбәрнамә белән түбәндәгеләрне раслыйм: ____________________________________

(шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты)

мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен билгеләнмәгән, шулай ук хокукларны дәүләт теркәве өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслыйм ________________________________________________________________________.

(түләү документының реквизитлары)

Әлеге хәбәрнамә белән мин ________________________________________________

[фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)]

__________________________________________________________________________

шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм (төзүче физик зат булган очракта).

| ____________________________ | ____________ | __________________________ |
|---|---|---|
| (юридик зат төзүче булып торган очракта, вазифасы) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Мөһер урыны
(булган очракта)

Әлеге хәбәрнамәгә теркәлә:

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 511 статьясындагы 16 өлешендә, 22 өлешендә каралган документлар (әлеге белдерүне төзүче исеменнән эскроу счетыннан файдаланып төзелеш подряды килешүе нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзү эшләрен башкаручы зат җибәргән очракта))

____________________